КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1231

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 октябрь, 952 нче; 2022 ел, 15 гыйнвар, 16 нчы; 2022 ел, 20 июль, 698 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә вәкаләтле орган тарафыннан, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

7 пунктның дүртенче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин